# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

14.03.2016 № 18

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 13 марттагы җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2016 елда Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме | Планлаштырылган чаралар | Сату өчен акча күләме /сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга мотопомпа,пожарный рукав сатып алу;: | 11500 |
| 2 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | Сеҗе авылында чишмә ремонтлау,<br>Сеҗе<br>Ташкич<br>Иске Масра<br>Сикертән<br>Җирлек территориясендәге авылларда светильникларны алмаштыру<br>Авылларда агачларны кису<br>Новое Чурилино<br>Иске Масра<br>Гөберчәк | <br><br>33700<br>15800<br>17900<br>6000<br><br>16000<br><br><br>9000<br>2000<br>2000 |
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту;:<br>Курса Почмак<br>Разъезд Курса<br>Югары Масра<br>Иске Муй | <br><br>15000<br>23000<br>5300<br>16100 |
| 4 | Җирлекнең җирле | - юлларны ремонтлау (вак таш, | 154700 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | торбалар сатып алу)<br><br>-кыщ көне кардан чистарту | 33800 |
| 5 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Курса Почмак | 4000 |
| 6 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру | вакытлыча складлау урыннарын карап тоту барлык торак пунктлар буенча каты коммуналь калдыклар җыю һәм чыгаруны оештыр | 11500 |
| | ИТОГО | - | 377300 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1897 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны - 1585, бу 83,55% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 1405 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 88,64% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 180 кеше тавыш бирде, бу 11,36% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

“2016 елда Сеҗе авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең исеме | Планлаштырылган чаралар | Сату өчен акча күләме /сум. |
|---|---|---|---|
| 1 | Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - торак пунктларга мотопомпа,пожарный рукав сатып алу;: | 11500 |
| 2 | Төзекләндерү эшләрен оештыру | Сеҗе авылында чишмә ремонтлау,<br>Сеҗе<br>Ташкич<br>Иске Масра<br>Сикертән<br>Җирлек территориясендәге авылларда светильникларны алмаштыру<br>Авылларда агачларны кису<br>Новое Чурилино<br>Иске Масра<br>Гөберчәк | <br><br>33700<br>15800<br>17900<br>6000<br><br>16000<br><br><br>9000<br>2000<br>2000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Күмү урыннарын карап тоту | - зират коймаларын урнаштыру һәм карап тоту;:<br>Курса Почмак<br>Разъезд Курса<br>Югары Масра<br>Иске Муй | <br><br>15000<br>23000<br>5300<br>16100 |
| 4 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларны ремонтлау (вак таш, торбалар сатып алу)<br><br>-кыщ көне кардан чистарту | 154700<br><br><br>33800 |
| 5 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Курса Почмак | <br>4000 |
| 6 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру | вакытлыча складлау урыннарын карап тоту барлык торак пунктлар буенча каты коммуналь калдыклар җыю һәм чыгаруны оештыр | 11500 |
| | ИТОГО | - | 377300 |

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе — Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре — Л. И. Нурмиева